**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2016 елны Татарстан Республикасында Су саклау зоналары елы дип игълан итү турында**

Су объектларын саклау һәм торгызу, биологик су ресурсларының, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының башка объектларының яшәү тирәлеген саклау, халыкка уңайлы шартлар тудыру мәсьәләләренә җәмгыятьнең игътибарын җәлеп итү максатларында **карар бирәм**:

1. 2016 елны Татарстан Республикасында Су саклау зоналары елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай эчендә Татарстан Республикасында Су саклау зоналары елын уздыру буенча оештыру комитетын төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай эчендә Татарстан Республикасында Су саклау зоналары елын уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Су саклау зоналары елы кысаларында чаралар уздыру буенча эшне оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Су саклау зоналары елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыятенә, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Су саклау зоналары елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 04 декабрь
№ ПУ-1162